Республика Татарстан

Совет Менделеевского муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы Советы

РЕШЕНИЕ КАРАР

29.12.2023 ел Менделеевск ш. №231

**Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 2 ноябрендәге 99-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә,

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының 2017 елның 8 августындагы 106 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2.5 бүлегендәге 17 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

1.2. Нигезләмәнең 2.5 бүлегендәге 20 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. Муниципаль хезмәткәргә класслы чин бирү турындагы карар, әлеге бүлекнең 13 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш, җирле үзидарәнең органына яисә вазыйфаи затына барлык кирәкле документлары булган класслы чин бирү турындагы тәкъдим кертелгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.».

1.3. 2.5 бүлегендәге 11 пунктчасында икенче җөмләне төшереп калдырырга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatarstan.ru урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының законлылыкны, хокук тәртибен һәм кеше хокукларын саклау буенча даими комитетына йөкләргә.

Совет рәисе Р.И. Беляев